КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2025 ел, 10 март г.Казань № 6-485

Татарстан Республикасы Рәисенең 2024 елның 19 декабрендәге 400 номерлы боерыгы нигезендә:

1. Бу боерыкка теркәлгән Татарстан Республикасында туристлык эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салуның өстенлекле юнәлешләре өлкәсендә үзара хезмәттәшлек регламентын расларга.

2. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына һәм Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 10 март, б-485 нче
боерыгы белән расланды

# Татарстан Республикасында туристлык эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салуның өстенлекле юнәлешләре өлкәсендә үзара хезмәттәшлек регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Икътисад министры белән Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының Татарстан Республикасында туристлык тармагын үстерүне тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы дәүләт программаларын һәм Татарстан Республикасында «Туризм һәм кунакчыллык» илкүләм проекты составындагы төбәк проектларны, тармак стратегияләре проектларын, туристлык тармагын үстерү программаларын һәм комплекслы планнарын гамәлгә ашыру буенча үзара хезмәттәшлек итү тәртибен билгели.

1.2. Татарстан Республикасында туристлык эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салуның өстенлекле юнәлешләре өлкәсендә үзара хезмәттәшлектә катнашучылар:

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры – Татарстан Республикасында туристлык эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салуның өстенлекле юнәлешләре өлкәсендәге эшчәнлек кураторы (алга таба – Куратор);

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты).

## 2. Үзара хезмәттәшлекнең максатлары һәм юнәлешләре

2.1. Татарстан Республикасында туристлык эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салуның өстенлекле юнәлешләре өлкәсендә үзара хезмәттәшлек түбәндәге максатларда гамәлгә ашырыла:

туристлык тармагының Татарстан Республикасы икътисадына өлешен арттыру;

инфраструктураны үстерү һәм туристлык хезмәтләренең сыйфатын яхшырту;

туристлык индустриясенә инвестицияләр җәлеп итү;

туризм өлкәсендә идарә функциясен гамәлгә ашыруда Дәүләт комитетына ярдәм күрсәтү.

2.2. Татарстан Республикасында туристлык эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салуның өстенлекле юнәлешләре өлкәсендә үзара хезмәттәшлек түбәндәге юнәлешләр буенча гамәлгә ашырыла:

туризм өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру;

Татарстан Республикасында туристлык индустриясен үстерү өчен уңайлы шартлар тудыруга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру;

туризм өлкәсендә хөкүмәтара килешүләрне гамәлгә ашыруда катнашу;

Татарстан Республикасында туризмны үсешенең өстенлекле юнәлешләренә ярдәм чараларын гамәлгә ашыру;

Татарстан Республикасының туристлык продуктларын эчке һәм дөньякүләм туристлык базарларына чыгаруда булышлык күрсәтү.

3. Үзара хезмәттәшлекне оештыру тәртибе

3.1. Куратор:

Татарстан Республикасында туризм өлкәсенең өстенлекле юнәлешләрен һәм үсеш стратегиясен билгеләүне координацияли;

Татарстан Республикасында туризм өлкәсендә дәүләт сәясәтенең бурычлары һәм өстенлекләре куелышын координацияли;

Дәүләт комитетының Татарстан Республикасы Рәисе адресына юлланган финанс характерындагы хатлары, Дәүләт комитетының Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министры адресына юлланган стратегик характердагы хатлары проектларын килештерә;

үзара хезмәттәшлек юнәлешләре кысаларында кирәкле мәгълүматларны һәм Дәүләт комитеты эшчәнлеге турындагы хисапларны соратып ала;

кирәк булуга карап, әмма айга кимендә бер тапкыр, Дәүләт комитеты белән берлектә, агымдагы мәсьәләләр буенча фикер алышу һәм уртак стратегияләр эшләү өчен киңәшмәләр үткәрә;

Дәүләт комитеты тарафыннан туризм өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү буенча эшләгән тәкъдимнәрне карап тикшерә.

3.2. Дәүләт комитеты:

туризм өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү буенча тәкъдимнәр булдыра һәм карап тикшерү өчен Кураторга җибәрә;

Куратор белән эшчәнлекнең төп юнәлешләре буенча Дәүләт комитеты эшчәнлеге планнарын килештерә;

Дәүләт комитетының Татарстан Республикасы Рәисе адресына юлланган финанс характерындагы хатлары, Дәүләт комитетының Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министры адресына юлланган стратегик характердагы хатлары проектларын Кураторга карап тикшерүгә җибәрә;

Татарстан Республикасында туристлык тармагын үстерүне тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы дәүләт программаларын һәм Татарстан Республикасында «Туризм һәм кунакчыллык» илкүләм проекты составындагы төбәк проектларны, тармак стратегияләре проектларын, туристлык тармагын үстерү программаларын һәм комплекслы планнарын гамәлгә ашыруга анализ бирелгән мәгълүматны әзерли;

агымдагы мәсьәләләр буенча фикер алышу һәм уртак стратегияләр эшләү өчен Куратор белән киңәшмәләр әзерләүне тәэмин итә;

Кураторның рәсми соравы буенча кирәкле мәгълүматны һәм агымдагы эшчәнлек турында хисаплар бирә.

3.3. Үзара хезмәттәшлек уртак киңәшмәләр оештыру һәм уздыру, түгәрәк өстәлләрдә, киңәшмәләрдә һәм башка чараларда катнашу, законнар нигезендә Дәүләт комитетына йөкләнгән бурычларны һәм функцияләрне башкаруга турыдан-туры бәйле мәгълүмат алмашу юлы белән, шулай ук әлеге Регламентның 2.2 пунктында

билгеләнгән юнәлешләрне гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган башка рәвешләрдә даими нигездә гамәлгә ашырыла.